Местное время. Воскресенье 14.00 «Своя игра» (0+) стый свет» (12+)

# «Библиотөн – 2025»

**Үткән атнада район балалар китапханәсендә «Библиосумерки», аннары район үзәк китапханәсендә традицион очрашу – Ватанны саклаучылар елына һәм Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган «Библиотөн – 2025» Бөтенрусия акциясе узды.**

Сәламләү сүзләре белән районның мәдәният һәм яшьләр сәясәте идарәлеге начальнигы Илгиз Харисов һәм үзәкләштерелгән китапханәләр системасы директоры Рәвил Әхмәтов чыгыш ясадылар.

Чарада тамашачыларга җырлар, «Үткән еллар тере хәтере» театральләштерелгән тамашасы, «Окоп шәмнәре ясау» осталык дәресләре күрсәтелде. Финал өлеше Ватанны саклаучылар елына һәм Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган «Сугыш юллары буйлап» интеллектуаль турниры булды. Соңыннан катнашучыларга дипломнар һәм сертификатлар тапшырылды. Шулай ук «Не смолкнет слава тех великих лет» фотозонасы оештырылган иде. Анда теләгән һәркем фотога төшә алды. Чарага килүчеләргә тәмле чәй тәкъдим ителгән «Библиокафе» да эшләде.

Чара дәвамында сугыш еллары җырлары һәм фронтовик шагыйрьләрнең шигырьләре яңгырады.

**Эльвина НИЗАМОВА.**

